**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Победа торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**20 октябрь 2023 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Победа торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) Җиңү бистәсендә урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Күпфатирлы торак йортларны су кертү системаларын төзү һәм ремонтлау: Җиңү бистәсе, Үзәк ур., 11 һәм 13 й.

3) Җиңү торак пункты халыкның күпләп ял итү урыннарын, аларга якын урнашкан территорияләрны төзекләндерү.

3) Җиңү торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

4) Җиңү бистәсендә традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: Г.И. Аскарова